**СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

*Юрид. адрес: 423984, РТ, Муслюмовский район, с. Октябрь, ул. Молодежная, д.3а.*
*Факт. адрес: 423984, РТ, Муслюмовский район, с. Октябрь, ул. Центральная, д.33А.*
Okt.Mus@tatar.ru *тел. 8(8-5556) 3-51-26*
ИНН 1629001152, КПП 162901001, ОГРН 1021605557863, ОКАТО 92242860001

Октябрь авылы «21» сентябрь 2020 ел

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ I УТЫРЫШЫ

**РЕШЕНИЕ** **№ 4** **КАРАР**

«Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибен расларга.

Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Октябрь авыл җирлеге территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

Октябрь авыл
җирлеге башлыгы И.М. Ханнанов

Мөслим муниципаль районы
Октябрь авыл җирлеге
Советының 21.09.2020 ел, 4 нче
санлы карары белән расланган.

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы « Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү Тәртибе.

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба – авыл җирлеге) һәм Татарстан Республикасы «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары (алга таба – район) арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзүнең әлеге тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон) нигезендә эшләнгән.

2. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында Районның җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзергә хокуклы.

Шул ук вакытта Районның җирле үзидарә органнары, Җирлек территориясендә, авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча районның Җирле үзидарә органнарына аерым вәкаләтләр бирү турындагы килешүләр нигезендә гамәлгә ашыра.

3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыруны Җирлек һәм Районның җирле үзидарә органнары тәкъдим итә ала.

4. Авыл җирлеге Башкарма комитеты үз инициативасы белән яисә районның җирле үзидарә органнары инициативасын карап, 30 көн эчендә җирле әһәмияттәге

мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында Җирлек Советы карар проектын әзерли.

5. Җирлек муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җирлек Советына норматив-хокукый актлар керткәндә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында җирлек Советы карары проектын кертә.

6. Җирлек Советы җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен район җирле үзидарә органнарына тапшыру турында Карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны Район җирле үзидарә органнарына карауга җибәрә.

7. Район Советы тарафыннан Җирлек Советы карарын уңай карау нәтиҗәсендә, җирлекнең җирле үзидарә органнары һәм районның җирле үзидарә органнары арасында килешү төзелә.

Күрсәтелгән килешү билгеле бер вакытка төзелергә, аның гамәлдә булуын туктату (шул исәптән вакытыннан алда) нигезләрен һәм тәртибен, әлеге өлештә күрсәтелгән бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү тәртибен, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган нигезләмәләрне, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрен күздә тотарга тиеш.

Килешү проектын эшләү өчен һәр яктан тигез санда вәкилләрне кертеп, эшче төркем төзелергә мөмкин. Эшче төркем үз эше нәтиҗәләре буенча килешү якларының мәнфәгатьләрен максималь рәвештә исәпкә алучы килешү проектын әзерли.

8. Җирлек Советы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Районның җирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар проектын кире каккан очракта, инициативаны җибәргән районга үзләре башлап җибәргән мәсьәләне карау нәтиҗәләре турында хат юллана.

9. Килешүдә каралган вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле финанс чаралары бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә. Бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмаган очракта, алар Җирлек бюджетына ун көн эчендә кайтарылырга тиеш.

Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертларны тапшыру максатларында, бюджет законнары нигезендә, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар, каралган район һәм җирлекләр бюджеты турындагы карарларга үзгәрешләр кертелә.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларны формалаштыру, санап чыгару һәм исәпкә алу Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен бирелә торган финанс чаралары ай саен тигез өлешләр белән күчерелә, шулай ук финанс чараларының бөтен суммасын бер үк вакытта күчерү мөмкин.

10. Вәкаләтләрнең бер өлеше, гамәлгә ашыру өчен кирәк булганда, муниципаль мөлкәт, түләүсез ашыгыч файдалану шартнамәсе нигезендә тапшырыла.Түләүсез файдалану шартнамәсе ашыгыч санала һәм Килешүнең гамәлдә булу срогында төзелә.

11. Күрсәтелгән килешүләр нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Районның җирле үзидарә органнарының муниципаль берәмлекләренең Вәкиллекле органы карарында каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга хокуклы.

12. Вәкаләтләрне тапшырган җирлекнең җирле үзидарә органы, тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, тапшырылган финанс чараларыннан һәм матди ресурслардан файдалану турында кирәкле мәгълүмат соратып ала ала.

13. Килешүнең гамәлдә булуы түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

– Якларның килешүе буенча;

– Якларның берсе үз йөкләмәләрен үтәмәгән, яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, берьяклы тәртиптә.

14.Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы, Районның җирле үзидарә органы, файдаланылмаган финанс чараларын һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди ресурсларны һәм мөлкәтне кире кайтара.

15.Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр сөйләшүләр һәм башка килештерү процедуралары юлы белән хәл ителә. Бәхәсне, сөйләшүләр уздыру яки килештерү процедураларын үткәрү юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул законнарда каралган башка тәртиптә каралырга тиеш.